ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2024 п.г.т.Алексеевское № 66

**Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 30.12.2022ел, №585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында»» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«2023-2025 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын финанслау күләме үзгәрү сәбәпле һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.02.2022 № 244-р боерыгы нигезендә;

**карар бирәм:**

1. «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында»» 2022 елның 30 декабрендәге 585 номерлы Башкарма комитет карары белән расланган «2023-2025 елларга Алексеевск муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә (алга таба Программа):

- Программаның 6 бүлеген «Программаны финанс белән тәэмин итү» таблица ( 1 нче кушымта) белән тулыландырырга.
- Программаның 7 бүлеген «Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү» таблицасы белән тулыландырырга (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А.Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма
комитетының
19.02.2024 № 66
карарына 1 нче кушымта

<table>
<tr><th rowspan="2">№ т/б</th><th rowspan="2">Чара исеме</th><th colspan="3">Финанс чыгымнары (җирле бюджет) мең сум</th><th rowspan="2">Гомум</th></tr>
<tr><th>2023</th><th>2024</th><th>2025</th></tr>
<tr><td rowspan="4">1</td><td rowspan="4">ТР АМР «Кышкы спорт төрләре буенча СМ» ӨББ МБУ эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү, Алексеевск муниципаль районы спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм хоккей буенча Россия Федерациясе Идел буе федераль округы Беренчелегендә катнашуы (подгруппа А)</td><td>342,26</td><td>-</td><td>-</td><td>342,26</td></tr>
<tr><td colspan="3">Финанс чыгымнары (республика бюджеты) мең сум</td><td rowspan="2">Гомум</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2024</td><td>2025</td></tr>
<tr><td>8002,7</td><td>65,7</td><td>-</td><td>8068,4</td></tr>
<tr><td colspan="2">ГОМУМ:</td><td>8344,96</td><td>65,7</td><td>-</td><td>8410,66</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
19.02.2024 № 66
карарына 2 нче кушымта

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. Спорт төрләрен үстерүдә өстенлекләр | | | |
| 6.1 | Алексеевск муниципаль районы спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм хоккей буенча Россия Федерациясе Идел буе федераль округы Беренчелегендә катнашуы (подгруппа А) | 2023-2024 | ББП һәм СТЯЭБ, МБ |